ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

25 гыйнвар, 2024 ел № 30/7

Шәһәр Советының даими комиссияләре турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, шәһәр Уставы, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советы Регламенты нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының 2011 елның 26 маендагы 12/8 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының даими комиссияләре турында Нигезләмәгә (Шәһәр Советының 2014 елның 10 июлендәге 31/22, 2015 елның 17 декабрендәге 4/14, 2018 елның 10 августындагы 26/15, 2019 елның 23 маендагы 31/14, 2023 елның 3 ноябрендәге 9/7 номерлы Карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 11 статьяда:

- 16 абзацны көчен югалткан дип танырга;

- 20 абзацта «, шулай ук су объектларын рекреацион максатларда куллану кагыйдәләре.» сүзләрен өстәргә;

2) 14 статьяда:

- 7 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- балалар һәм яшьләр белән эшләү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда катнашу, яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау чараларын эшләү һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре буенча муниципаль программаларны эшләү һәм гамәлгә ашыру, шәһәрдә яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның мониторингын оештыру һәм тормышка ашыру;».

2. Әлеге Карар рәсми басылган көннән үз көченә керә, әлеге Карарның 1 пункт 1 пунктчасындагы икенче абзац 2024 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

3.Әлеге Карар үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының регламент, хокук тәртибе һәм халык иминлеген тәэмин итү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев